# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Заводская урамы (1 йорттан 12А йортка кадәр) гражданнарыннан  үзара салым кертү турында**

**21 октябрь 2022 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакй шәһәре  Заводская урамы (1 йорттан 12А йортка кадәр) гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» (Заводская урамы (1 йорттан 12А йортка кадәр) яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы студентларыннан, гайлә әгъзасы махсус хәрби операциягә юнәлтелгән гаиләләрдән кала һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең Заводская урамы 1 йорттан 12А йортка кадәр җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (юлларны асфальт-бетон белән каплау, төяү, ташу, асфальт-бетон салу, шартнамә буенча эшләр башкару) ».».

3. Әлеге карарны  кабул ителгән көннән алып 2 көн эчендә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru..

Гражданнар җыенында рәислек итүче: А.Ф.Хәлиуллин